РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ КИЯТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫЯТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.10.2020 ел № 1-4

Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү белән бәйле беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аерым категория затларның вазыйфаи хәле яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүләре белән бәйле рәвештә бүләк алуы турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 09.01.2014 елның 09 гыйнварындагы 10 номерлы карары (2015 елның 12 октябрендәге 1089 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары редакциясендә) нигезендә,ТР Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. ТР Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 декабрендәге 83-2 номерлы карары белән расланган, Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү белән бәйле беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү хакындагы нигезләмәгә (алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 14 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгәнчә, гариза бирелмәгән бүләк, Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итү комиссиясе бәяләмәсен исәпкә алып кулланыла.».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземә йөклим.

Буа муниципаль районы Кыят авыл
җирлеге башлыгы Е.С. Корунова